Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

5 ноябрь, 2025 ел № 3

Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябредәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Пимәр авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Пимәр авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

Пимәр авылында. Үзара салымны ике этапта кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабын 2025 елның 21 ноябрендә 9.00 сәгатьтә Совет урамы, 25А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Совет, Яшьләр урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;
- гражданнар җыенының икенче этабын 2025 елның 21 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Совет урамы, 25А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Пионер урамында теркәлгән халыкны кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Пимәр торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 1500 сум

күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

торак пункт территорияләрен төзекләндерү;

торак пункт чикләрендә гомуми кулланылыштагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Юныс авылында. 2025 елның 21 ноябрендә 11.00 сәгатьтә Комсомол урамы буенча 14 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2026 елда Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлегенең Юныс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә килешәсезме:

- гомуми файдаланудагы урыннарын төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов